ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 1211 «30» 09 2016 ел

Мамадыш муниципаль районы гражданнарын хәрби хезмәткә чакыру һәм аларны 2016 елның көзендә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә җибәрү турында

Мамадыш муниципаль районы гражданнарын хәрби хезмәткә чакыру максатында , «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының "Хәрби комиссариатлар турында Нигезләмәне раслау турында"2007 елның 1 сентябрендәге 1609 номерлы Указы, "Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә чакыру турындагы нигезләмәне раслау турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 11 ноябрендәге , № 663 карары нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Бүлек башлыгына (Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Мамадыш муниципаль районы буенча) аларның чакырудан кичектерү хокукы 2016 елның 31 декабренә кадәр тәмамлана торган 1989-1998 елларда туган гражданнарны һәм аларга 18 яшь тула 2016 елның 31 декабренә кадәр тула торган 1998 елда туган гражданнарны хәрби хезмәткә чакыруны оештырырга тәкъдим итәргә.

2. Мамадыш муниципаль районының чакырылыш комиссиясенә 2016 елның 31 декабренә кадәр хәрби хезмәткә чакыруны кичектерү хокукы бетә торган 1989-1998 елгы гражданнарны һәм 2016 елның 31 декабрендә 18 яше тула торган 1998 елгы гражданнарны 2016 елның 1 октябреннән 31 декабренә кадәр Мамадыш муниципаль районының чакырылыш участогында хәрби хезмәткә чакыруны гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Мамадыш муниципаль районы буенча бүлегенә, «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» ДАССОга һәм район чакырылыш комиссиясенә 2016 елның 1 октябреннән 31 декабренә кадәр хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарга медицина таныклыгы бирүне, аларны медицина тикшерүен һәм дәвалауны оештыруны һәм гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә.

5. Беренче махсуслашкан һәм белгечлеге буенча гамәлдә булган сертификатлары булган, хәрби-табиб экспертизасы өлкәсендә эш тәҗрибәсе булган табиблардан бүлеккә (Татарстан Республикасының Мамадыш районы буенча хәрби

комиссариаты, муниципаль) хәрби-табиб комиссиясен әзерләргә һәм расларга (1 нче кушымта).

6. Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле Россия Федерациясе гражданнарын амбулатор (стационар) медицина тикшерүе (дәвалау) уздыру өчен 2016 елның октябрь - декабрендә, шулай ук Мамадыш районының чакырылыш комиссиясе тарафыннан хәрби хезмәткә яраксыз дип танылган медицина учреждениеләре исемлеген (килешү буенча) расларга (2 нче кушымта).

7. Россия Эчке эшләр министрлыгының Мамадыш районы буенча бүлеге башлыгына чакыру уздыру чорында озак вакытка эзләнүдә булган гражданнарны һәм хәрби хезмәткә чакырудан качучы гражданнарны эзләү чараларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле сандагы хезмәткәрләрне бүлеп бирүне тәкъдим итәргә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль районның Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.П. Смирновка йөкләргә.

Җитәкче И.Э.Фәттахов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
30.09 2016 ел, № 1211 карарына
1 нче кушымта

Белгечләр һәм урта медицина персоналы бүлегендә (Татарстан Республикасы Мамадыш районы буенча хәрби комиссариатында, муниципаль) беренчел махсуслашкан һәм белгечлеге буенча гамәлдәге сертификатлары булган хәрби-табиб комиссиясе исемлеге.

| Белгечләр исемлеге | төп состав | Резерв состав |
|---|---|---|
| Баш табиб | Галиев Р.К. | Гилаев М.М. |
| Отоларинголог | Галиев Р.К. | Федорова Е.В. |
| Хирург | Нуруллин И.М. | Габдрахманов Н.Н. |
| Невролог | Сафин М.Г. | Фархуллин И.С. |
| Офтальмолог | Хаҗиев И.С. | Бондаренко П.С. |
| Терапевт | Гилаев М.М. | Азизова З.А. |
| Стоматолог | Биктимеров Р.Н. | Димиева А.Г. |
| Психиатр | Бессонова К.В. | врач РКПБ Николаев Л.Н. |
| Дерматовенеролог | Тимербаев Р.К. | Солтанов Б.Н. |
| Секретарь ВВК | Осинина А.В. | Донскова Е.Г. |
| Отларингология кабинетының шәфкать туташы | Шәйдуллина Ф.Н. | Вәгыйзова Р.А. |
| Психиатрия кабинетының шәфкать туташы | Газимова А.Н. | Каримова Н. Г. |
| Офтальмология кабинетының шәфкать туташы | Фатыхова Г.Р. | Хабибрахманова Г.В. |
| неврология кабинетының шәфкать туташы | Сафина Р.Ф. | Нургалимова А.Г. |
| Хирургия кабинеты шәфкать туташы | Шәйхетдинова Р.К. | Гайфутдинова М.М. |
| Табиб-терапевтның шәфкать туташы | Рәхимова Н.Н. | Гилаева А.Г. |
| Поликлиниканың шәфкать туташы | Әхмәрова Р.М. | Гимадеева В.В |

Муниципаль район
башкарма комитеты
җитәкчесе урынбасары А.П. Смирнова

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
30.09 2016 ел, № 1211 карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле Россия Федерациясе гражданнарының, шулай ук Мамадыш районының чакырылыш комиссиясе тарафыннан хәрби хезмәткә яраксыз дип танылган амбулатор (стационар) медицина тикшерүе (дәвалау) уздыру өчен медицина учреждениеләре исемлеге.

1. 1. «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» ДАССУ
2. Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау учреждениеләре:

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» ДАССУ

«Төбәкара клиник-диагностик үзәк» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 1 һәм 2 поликлиника бүлекләре;

3. «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының В.М. Бехтерев исемендәге республика клиник психиатрия хастаханәсе» ДАССУ;
4. «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика наркология диспансеры» ДАССУ
5. «Туберкулезга каршы Республика клиник диспансеры» ДАССУ;
6. “Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры” ДАССУ;
7. “Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник офтальмологик хастаханәсе” ДАССУ;
8. “Республика клиник тире-венерология диспансеры” ДАССУ;
9. “Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының СПИД һәм йогышлы авыруларны профилактикалау һәм көрәш буенча республика үзәге” ДАССУ;

10. «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика стоматология поликлиникасы» ДАССУ;

11. “А.Ф. Агафонов ис. Республика клиник инфекция хастаханәсе” ДАССУ;

12. “Казан эндокринологик диспансеры” ДАССУ

3. Казан шәһәрендә сәламәтлек саклау учреждениеләре:

10. Казан шәһәренең «7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССУ;

11. “Студентларның 4 нче шәһәр поликлиникасы” ДАССУ

4. Сәламәтлек саклауның резерв учреждениеләре:

- “Казан (Идел буе) федераль университеты” югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең МСЧ;
- Казан шәһәренең «Медицина университеты клиникасы» ДАССУ;

- «Төбәкара клиник-диагностик үзәк» ДАССУ тәүлек буе эшли.

Аерым очракларда Татарстан Республикасы хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнар Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын гамәлгә ашыруда катнашучы Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау учреждениесен тикшерүгә (дәвалауга) җибәрелергә мөмкин.

Муниципаль район
башкарма комитеты
җитәкчесе урынбасары А.П. Смирнова